Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

9 август 2012 ел № 214

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының “Өч һәм өчтән дә артык балалары булган гражданнарга, аларга тиешле шәһәр яки авыл җирлеге чикләрендә формалашкан җир участоклары булмаган очракта, җир участоклары бирү турында”

“Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе, 6 нчы пункты, “Россия Федерациясендә җирле үзиадарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы” 2003 елның 6 октябрендәге № 131 Федераль Закон нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 нче маддәсе, 1 һәм 3 подпунктларында каралган максатларга, җир участогы алу белән кызыксынган, Әлмәт муниципаль районы составындагы шәһәр яки авыл җирлегендә даими яшәүче гражданнарга җир участоклары, әлеге гражданнар даими яши торган шәһәр яки авыл җирлеге чикләрендә формалашкан җир участоклары булмаган очракта, Әлмәт муниципаль районы составына кергән башка торак пункт чикләрендә формалашкан җир участокларыннан бирелә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә “Знамя труда”, “Әлмәт таңнары” газеталарында басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек даими комиссиясенә (А.И.Верия) йөкләргә.

Әлмәт муниципаль районы башлыгы М.Х. Салихов